Чыганак: **<u>Шәһри Казан.- 2006.- 16 июнь.</u>**

# Казан - балет сәнгате үзәге

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында «Йосыф» балеты өчен Мәскәүдә Россия Федерациясенең Дәүләт премиясен алып кайткан либретто авторы, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Леонид Любовский, Татарстанның атказанган артисты Нурлан Канетов катнашында матбугат конференциясе узды. Конференциядә шулай ук М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов, театр әһелләре берлеге рәисе Ринат Таҗетдинов, сәнгать җитәкчесе Владимир Яковлев бар иде.

«Йосыф» балеты инде өч ел рәттән әлеге премиягә тәкъдим ителеп килгән иде. Быел, ниһаять, ул үзенең лаеклы бәясен алды.

**Л.ЛЮБОВСКИЙ**: «Әлеге балет 5 ел бара. Бу - безнең уртак, бердәм эшебез нәтиҗәсе. Без аерым -аерым итеп тулы канлы бербөтен организм тудырдык. Ренат Харис аның аңы-акылы, Рәүфәл Мөхәммәтҗанов йөрәге булса, мин балетның җаны булып торам. Балетның музыкасы өстендә мин бик озак эшләдем. Бер кырыемда - Коръән, икенчесендә Тәүрат (Библия) торды. Мин мәңгелек рухы иҗат итәргә тиеш идем. Мөмкинлекләремнең чигендә эшләдем. Икенче тапкыр шундый эш йөкләсәләр, барып чыкмас кебек. «Йосыф»ны «тудыруны» сүзгә генә күчереп кенә аңлатып та бирә алмыйм. Бер караганда, без Кол Галидән шактый ераклаштык та тәсле. Әмма без куелышның соңын балетча итеп тәмамларга тиеш идек».

**Р.ХАРИС:** «Әгәр сез бу хезмәт ничек башланды, дип сорасагыз, Леонид Любовскийның миңа булган мөрәҗәгате дияр идем. Ул миннән либретто язуны сорады. «Йосыфка кадәр ул минем шигырьләремнән «Фикер» («Мысль») исемле вокал циклы әзерләгән иде. Әлеге циклны ишеткәч, минем исем киткән иде. Любовскийның нәкъ менә миңа мөрәҗәгать итүенә шатландым. Без яшәгән дөнья көннәнкөн вәхшиләнә, явызлана бара. Шул явызлыкны җиңү теләге белән мин әлеге либреттоны яздым. «Йосыф» балетын мин инде 16-17 тапкыр карыйм. Спектакль тәмамлануга залдан әсәрләнеп чыккан тамашачыга карап, канәгатьләнү хисе кичерәм. Ул кешене уйланырга, дулкынланырга, җирдә игелек белән яшәргә өйрәтә. Төп герой Йосыф искиткеч сыйфатка - кешеләрне кичерә белү сәләтенә ия. Аның шул сыйфаты илне зур фаҗигаләрдән саклап кала. Балет бүгенге вәхши, террор кабынып торучы илдә аеруча актуаль, дип уйлыйм. Сәхнәдә явызлыкны гәүдәләндерү күпкә җиңел. Изгелекне гәүдәләндерү зур талант һәм тырышлык сорый. Нурлан бу максатка иреште».

**Н.КАНЕТОВ:** «Спектакльне сәхнәгә куюы бик кыен булды. Баштагы мәлне тәнем ничектер карыша иде. Минем алда зур бурыч - авторларның әйтергә теләгән фикерен төкми-чәчми җиткерә белү, сәхнәдә изгелекне гәүдәләндерү максаты торды».

**В.ЯКОВЛЕВ:** «Сәхнәдәге рольне өч төрле башкарып була: әйбәт, профессиональ дәрәҗәдә һәм искиткеч. «Йосыф» - искиткеч зур хезмәт нәтиҗәсе. Нурлан искитмәле итеп уйный алды. Әлеге спектакль безнең репертуарыбызның йөзек кашына әйләнде. Мәскәүдә җиңеп кайтуыбыз өстебездәге «провинция» тузанын кагарга өйрәтергә тиеш. Чөнки бүгенге Казан ул - балет сәнгате үзәге».

**Р.МӨХӘММӘТҖАНОВ:** «Әсәр зур профессиональ иҗатчылар җимеше булып туды. Любовский - үз эшенең бөтен нечкәлекләрен белеп эш йөрткән, хис-тойгыларны музыкага күчерә алган профессионал, Ренат Харис шактый зур тәҗрибәле (мин монда аны шагыйрь буларак түгел, нәкъ менә театрны аңлый, якыннан белүе нисбәтеннән әйтәм), бик күп театр куелышларын карап чыккан талантлы шәхес. Әлеге ике шәхес тудырган әсәр театр әһелләре җаваплылыгына тапшырылды. Күпләр балет турында ниндидер калыплар уйлап тапса да, шуны әйтәсем килә: балетта бернинди төгәл формуланың булуы мөмкин түгел. «Йосыф» балетыннан исә мин беренче тапкыр тулы канәгатьләнү хисе кичердем. Текст, музыка, декорация, куелыш - иң югары дәрәҗәдә эшләнде. Әлбәттә, вакыт үзе хөкемдар, әмма бүгенге көндә әлеге балет турында мин опера һәм балет театры югары кимәлдәге сәнгать әсәре тудырды, дип әйтә алам».

**Р.ХАРИС:** «Иң сөенечлесе шул - беренче тапкыр милли республикада туган спектакль Россия Федерациясе премиясенә лаек дип табылды. Бу Татарстанның Россия халыкларының милли мәдәнияте үсешендә зур роль уйнавы турында сөйли».

**Гөлнара ҖӘЛИЛОВА.**